**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
## КАРАРЫ

2015 елның «5» февраленнән № 40-230

### Яңа Чишмә муниципаль районының 2014 елда социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2015 елга бурычлары турында

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В.М. Козловның «2014 елга Яңа Чишмә муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2015 елга бурычлар турында» хисабын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Яңа Чишмә муниципаль районы Советы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы үз вәкаләтләрен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе һәм законнары, Яңа Чишмә муниципаль районы Уставы нигезендә гамәлгә ашырды дип билгеләде.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының даими депутат комиссияләренең фикерләрен исәпкә алып, шулай ук Яңа Чишмә муниципаль районы Уставының район Башлыгының район халкы һәм район Советы алдында хисап тотуы турындагы нигезләмәләрен үтәп, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В.М. Козловның «2014 елга Яңа Чишмә муниципаль районының социаль-икътисади үсеш нәтиҗәләре һәм 2015 елга бурычлар турында» гы хисабын игътибарга алырга.

2. Яңа Чишмә муниципаль районы Советы депутатларына «2014 елда Яңа Чишмә муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2015 елга бурычлар турында» хисапны үз округларында сайлаучылар игътибарына җиткерергә.

**3. 2015 елда төп юнәлешләрне гамәлгә ашыру өчен:**

**3.1. Планлаштыру һәм икътисадый үсеш өлкәсендә (Л.К.Исхаковага** ):

- 2015 елда 2014-2016 елларга районның социаль-икътисадый үсеше муниципаль Программасының төп күрсәткечләрен үтәүне тәэмин итәргә;
- халыкка муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын күтәрергә, шул исәптән күп функцияле үзәк аша да;
- кризиска каршы чаралар кысаларында бюджетка салым һәм салым булмаган керемнәр буенча даими мониторинг үткәрергә, салым органнары белән

берлектә салымнарны вакытында түләүне оештыру буенча оператив чаралар күрергә;

- кече һәм урта бизнес субъектларының «Лизинг-грант»программасында катнашуын активлаштырырга;

- муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыкларына резидентларны җәлеп итү буенча эш алып барырга;

- район территориясенә инвестицияләр җәлеп итү буенча эшне активлаштырырга;

- хезмәт өчен түләүнең конвертлы формаларын ачыклау һәм хуҗалык итүче субъектлар белән хезмәттәшлек буенча килешүләр имзалау эшен көчәйтергә;

- товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне, сатып алуның нәтиҗәлелеген арттырырга, мондый сатып алуларны гамәлгә ашыруның ачыклыгын һәм үтә күренмәлелеген тәэмин итәргә, мондый сатып алулар өлкәсендә коррупцияне булдырмаска һәм башка явызларча куллануга юл куймаска;

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына арендага, милеккә бирү өчен муниципаль милек реестрын актуаль хәлдә тотарга;

- хезмәт базарында квалификацияле эшче көчләр тәкъдим итүне һәм ихтыяҗның туры килүен тәэмин итү буенча чаралар комплексын гамәлгә ашырырга;

- хезмәт базарында даими мониторинг алып барырга һәм халыкның мәшгульлегенә булышлык итү өчен чаралар комплексы кабул итәргә;

- бюджет учреждениеләре тарафыннан бюджет акчаларын экономияле файдалану буенча эш алып барырга, бигрәк тә энергия чыганаклары чыгымнарында;

- бюджет законнарын үтәп, берләштерелгән бюджетның сыйфатлы үтәлешен тәэмин итәргә;

- дәүләт һәм муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрен куллану нәтиҗәлелеген, шулай ук муниципаль милек һәм җир кишәрлекләрен муниципаль район мәнфәгатьләрендә, шул исәптән концессион килешүләр буенча арендага бирү нәтиҗәлелеген арттырырга;

- дәүләт һәм муниципаль милекне һәм җир кишәрлекләрен исәпкә алу системасын камилләштерү, шулай ук җиргә хокукый документларны рәсмиләштерү буенча эшне көчәйтергә.

**3.2. Авыл хуҗалыгы өлкәсендә (С.М.Барановка):**

- игенчелектә һәм терлекчелектә алдынгы технологияләрне гамәлгә кертү буенча чараларны дәвам итәргә, терлекләрнең баш санын 4% ка арттырырга, сөт, ит җитештерүне 2% тан да киметмәскә, шулай ук агросәнәгать комплексы хезмәткәрләренә хезмәт хакы үсешен 14000-14500 сумга кадәр арттырырга;

- федераль һәм республика максатчан программаларында катнашу аша авыл хуҗалыгы предприятиеләренең матди базасын ныгыту, терлекләрнең баш санын арттыру буенча чаралар күрергә;

- яңа эш башлаучы һәм үсеп килүче крестьян (фермер) хуҗалыкларына һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга, гаилә фермаларына ярдәм итәргә;

- фермер һәм шәхси ярдәмче хуҗалыклар җитештергән авыл хуҗалыгы продукциясен базарга чыгару буенча чаралар комплексын гамәлгә ашырырга;

- чәчүлек мәйданнарын саклап калу, сыйфатлы орлык материалы белән тәэмин итү, төрле ашламалар кертү һәм бөртекле культураларның

уңдырышлылыгын гектардан 21 центнердан да ким булмаган уңыш алу буенча чаралар күрергә;

- 2015-2020 елларга Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә агросәнәгать комплексын үстерү буенча муниципаль программаны эшләү һәм кабул итү.

**3.3. Төзелеш һәм ТКХ өлкәсендә (М.М.Гомәровка ):**

- торак-коммуналь хуҗалыгын модернизацияләүне, инновацион технологияләр, җылылык-су, энергия белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу , каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм утильләштерү өчен заманча материаллар кертүне дәвам итәргә;

- энергияне сак тоту һәм энергия нәтиҗәлелеген тәэмин итү буенча муниципаль программаны гамәлгә ашыру буенча эшне дәвам итәргә;

- торак, клублар төзелеше, күп фатирлы йортларны капиталь ремонтлау, гомуми белем бирү мәктәпләре һәм юллар төзелеше муниципаль программасын сыйфатлы тормышка ашыруны тәэмин итәргә;

- индивидуаль торак төзелеше темпларын саклап калу чараларын күрергә;

- торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр җыюны 100% тан да ким булмавына ирешергә.

**3.4. Социаль өлкәдә (В. Н.Семенякка):**

**Сәламәтлек саклау өлкәсендә:**

- халыкны канәгатьләндерә торган медицина хезмәтләренең сыйфатын күтәрергә;

- сабый һәм аналар үлеме очракларына юл куймаска;

- йөрәк кан тамырлары, онкология авыруларын иртә ачыклау буенча чаралар комплексын үткәрергә һәм шушы авырулардан үлүчеләр санын киметүгә ничек ирешергә;

- бала тудыру хезмәтләренең нәтиҗәлелеген арттыру;

- сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле медицина кадрлары белән тәэмин итү буенча чаралар күрергә;

- район халкын дарулар белән тәэмин итүне контрольгә алырга.

**Мәгариф өлкәсендә:**

- укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең сәламәтлеген саклау өлешендә белем бирү учреждениеләренә куркынычсыз белем бирү мохитен һәм федераль таләпләрне үтәүне тәэмин итә торган шартлар тудырырга;

- район мәгариф учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту эшен дәвам итәргә;

- чыгымнарны оптимальләштерү һәм сыйфатлы белем алуны тәэмин итү максатыннан мәгариф учреждениеләре челтәрен үзгәртеп кору эшен дәвам итәргә;

- гомуми белем бирүнең сыйфатын күтәрү, Бердәм дәүләт имтиханнарына әзерлек сыйфаты буенча чараларны оештыру өчен шартлар тудыру эшен дәвам итәргә, барлык фәннәр буенча да түбән чикне узучылар санын 100% ка һәм чыгарылыш сыйныф укучылары тарафыннан 100% аттестат алуга ирешергә;

-3 яшьтән өлкәнрәк балаларны мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә урыннар белән тәэмин итү эшен дәвам итәргә;

- «Дәрестән соңгы мәктәп» проекты кысаларында өстәмә белем бирү системасын үстерү кысаларында фәнни-техник иҗатны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны нәтиҗәле куллануны тәэмин итәргә.

**Халыкны социаль яклау өлкәсендә:**

- социаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәлелеген һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү өстендә эшләүргә;

- аз керемлеләргә, мохтаҗ категория гражданнарына, ветераннарга, инвалидларга адреслы социаль ярдәм күрсәтүне дәвам итәргә;

- Бөек Ватан сугышы ветераннарының торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булган гаиләләрне, шулай ук ветераннарның, инвалидларның башка категорияләрен, инвалид балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча эшләргә.

- халыкның төрле категорияләре тормышында тискәре тенденцияләрне киметүгә юнәлдерелгән эшне дәвам итегез;

**Яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсендә:**

- район спортчыларының республика, бөтенроссия ярышларында һәм бәйгеләрендә катнашуы буенча эшне активлаштыру;

- булган спорт базасыннан нәтиҗәлерәк файдаланырга, аның максималь йөкләнешен тәэмин итәргә;

- барлык яшьләр иҗтимагый оешмалары эшен активлаштырырга.

**Мәдәният өлкәсендә:**

- мәдәният хезмәткәрләренең һөнәри әзерлекләрен арттыру;

- талантлы яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү;

- муниципаль район территориясендә яшәүче халыкларның мәдәни үсеше, телләрен, гореф-гадәтләрен һәм традицияләрен саклау өчен тигез шартлар булдырырга;

**Коммерцияле булмаган иҗтимагый оешмалар өлкәсендә:**

- иҗтимагый коммерцияле булмаган оешмалар, яңа иҗтимагый оешмаларны һәм берләшмәләрне теркәү эшләрен активлаштырырга;

- иҗтимагый коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан грантлар һәм конкурсларда актив катнашырга ярдәм итәргә.

**3.5. Яңа Чишмә муниципаль районының Контроль-хисап палатасы (Р.А.Губкинга.):**

- Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты үтәлешен, муниципаль милек белән идарә итүдән алынган акчаларның бюджетка керүен тикшереп торуны көчәйтергә;

- бюджет процессында хокук бозуларны һәм тайпылышларны вакытында тикшерергә һәм анализларга.

**3.6. В области религии, межнациональных и межконфессиональных отношений (И.Х.Фәйзуллинга):**

- дини оешмалар тарафыннан күчемсез милек объектларына милек хокукын рәсмиләштерүдә ярдәм итәргә һәм чаралар комплексын тормышка ашырырга;

- дини оешмаларның иҗтимагый коммерцияле булмаган оешмалар өчен грантлар һәм конкурсларда катнашуы буенча эшне координацияләргә һәм мәгълүмат бирергә;

- чаралар комплексы үткәрергә, конфессияара мөнәсәбәтләр торышын мониторинглау һәм бәяләргә, конфликтлы ситуацияләргә оператив рәвештә җавап бирергә;
- Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә рухилыкны торгызуда ярдәм күрсәтергә.

4. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына хисап докладында әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне үтәү буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга, аның буенча фикер алышу вакытында 2015 елның 01 мартына кадәр һәм Яңа Чишмә муниципаль районы Советының чираттагы утырышына чыгарырга.

5. Район Башлыгы урынбасары Н.И. Попковага авыл җирлекләре Башлыклары белән берлектә түбәндәге юнәлешләрдә эшне дәвам итәргә тәкъдим итәргә:

- шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә кредитлар алу һәм уртача республика дәрәҗәсенә җиткерергә;
- үзара салым кертү буенча референдумны 2015 елның апрелендә үткәрергә;
- авыл җирлеге Уставларына үз вакытында үзгәрешләр кертергә, эшне җирле үзидарә вәкаләтләренә туры китереп башкарырга.

**6. Авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:**

- авыл җирлекләре Советлары утырышларында Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының хисабы буенча фикер алышырга һәм хисап докладында әйтелгән искәрмәләрдән чыгып, чаралар планын эшләргә;
- федераль, региональ һәм муниципаль программаларны гамәлгә ашыру нигезендә халыкның тормыш сыйфатын эзлекле рәвештә күтәрүне тәэмин итәргә;
- җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдә муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарының ролен арттырырга, муниципаль берәмлекләр депутатларының активлыгын арттырырга;
- җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен вакытында һәм сыйфатлы башкару эшен дәвам итәргә;
- яшьләрне авылда калдыру өчен кредит бирү һәм торак төзелеше өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган программаларны мөмкин кадәр күбрәк кулланырга;
- гариза бирүчеләрне документлар белән тәэмин итүдә һәм рәсмиләштерүдә конкрет ярдәм күрсәтергә;
- шәхси ярдәмче хуҗалыкларда терлекләрнең баш санын саклап калуны тәэмин итәргә;
- муниципаль районның җирле үзидарә органнарына, хокук саклау органнарына хокук бозуларны профилактикаларга, террорчылыкка каршы тору һәм җәмәгать тәртибен, гражданнарның тормышын, сәламәтлеген һәм абруен, милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуда, авыл җирлекләре территориясендә яшәүче мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясен тәэмин итүдә ярдәм күрсәтергә;
- торак пунктларны, зиратларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту, җирлек территорияләрендә экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча актив эш алып барырга.

7. «Яңа Чишмә хәбәрләре» газетасының баш мөхәрриренә җирле үзидарә органнары эшен газета битләрендә даими яктыртырга киңәш итәргә.

8. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам..

Яңа Чишмә
муниципаль район Башлыгы В. М. Козлов